**2011/12 нче уку елына урта (тулы) мәктәп курсы өчен татар теле һәм әдәбиятыннан язма имтихан үткәрү буенча сочинение комплектлары**

Татар мәктәпләренең XI сыйныфларында татар теле һәм әдәбиятыннан чыгарылыш имтиханы өчен материал 20 комплектка тупланып бирелде. Язма эшне башкару өчен 6 астрономик сәгать билгеләнде. Һәр комплектка, аерым номер куелып, 7 шәр тема тәкъдим ителә. Имтихан материалы татар теле һәм әдәбиятыннан гомуми белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумына туры китереп эшләнелде. Укучыларның борынгы әдәбият, XIX гасыр, XX йөз башы, совет чоры һәм хәзерге заман әдәбиятыннан белемнәре тикшерелә, шул сәбәпле һәр комплектка шушы юнәлештәге темалар сайланды.

Сочинение яздыру методикасы татар мәктәпләренең X-XI сыйныфлары өчен татар теле дәреслекләрендә һәм татар мәктәпләренең V–XI сыйныфлары өчен татар теле программаларында бирелгән.

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы

**№ 1**

1. “Гыйлем – һәр авырлыктан котылырга сәбәпчедер...” (Р.Фәхреддин иҗаты буенча).
2. Каюм Насыйри – үз халкының һәм үз чорының улы.
3. А. Гыйләҗев иҗаты буенча инша. (Теманы укучы үзе сайлый).
4. Гаилә-җәмгыятьнең нигезе.(Г.Кутуйның “Тапшырылмаган хатлар” повесте буенча)
5. Меңьеллык Казан.
6. “Без сугышта юлбарыстан көчлебез”. (Бөек Ватан сугышы татар әдәбиятында)
7. Алтын Урда чорында татар әдәбиятының яңарышы.

**№ 2**

1. Сафта барган Такташ җырларын
   Бүген бар да сөеп тыңлыйлар!
   (Ш.Галиев)
2. Муса Акъегетнең «Хисаметдин менла» романы – мәгърифәтчелек реализмы әдәбиятының беренче үрнәге.
3. Ә.Еники – психологик анализ остасы.
4. “Үз халкыңны үз итсәң,

Ят халыкка кол булмассың”. (Нурихан Фәттахның “Итил суы ака торур” романы буенча)

5. Гаяз Исхакый иҗатында милләт язмышы.
6. Тарих – халык хәтере.( Тарихи романнарга күзәтү)
7. Танылмыйдыр кеше гәрчә тышыннан,
   Танып була аны кылган эшеннән.
   (Дәрдемәнд)

**№ 3**

1. “Халык зур ул, көчле ул...”
2. Равил Фәйзуллин – минем яраткан шагыйрем.
3. Ризаэддин Фәхреддин иҗатында тәрбия-әхлак мәсьәләләре.
4. Г.Исхакыйның «Көз» повестенда мохитнең тәрбияви көче.
5. «Сигез гасыр элек җырларыңны
   Яраткан да халык ятлаган,
   Күңелендә көйләп саклаган”. (Кол Гали иҗаты буенча)
6. Татар  әдәбиятында хикәя жанры.
7. С. Хәким иҗатында туган як  темасы.

**№ 4**

1. Г.Ибраһимов иҗаты буенча инша. (Теманы укучы үзе сайлый)
2. Ф.Кәрим шигъриятендә гражданлык мотивлары.
3. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәре – халкыбызның рухи юлдашы.
4. Үкенмим: бар утым, бар көчем –
   Һәммәсе халыкка бирелде.
   (Ф.Яруллин)
5. Туфан Миңнуллин драмаларында шагыйрь образы.
6. Г.Исхакый драмаларында милли геройлар.
7. “Мәхәббәт,
   Ул үзе иске нәрсә,
   Ләкин
   Һәрбер йөрәк аны яңарта...”
   (Һади Такташ.“Мәхәббәт тәүбәсе”)
   Татар шигъриятендә мәхәббәт лирикасы.

**№ 5**

1. Г.Исхакыйның «Ул әле өйләнмәгән иде» әсәрендә мәхәббәт һәм гаилә проблемасы.
2. Татар әдәбиятында һәм сәнгатендә Муса Җәлил образы.
3. Һәркемгә дә бирелмәгәндер ул
   Яшьнәү-күкрәүләргә тиң гомер. (Н.Нәҗми)

Ф.Яруллинның тормышы һәм иҗаты турында языгыз.

4. Һ.Такташ иҗатында яшьлек һәм мәхәббәт темасы.
5. Тукайның балалар өчен язган шигырьләрендә әхлак-тәрбия мәсьәләләре.
6. Онытсак үткәнне, оныклар
   Санламас бүгенге кадерен.
   (Ә.Маликов)
7. Утыз Имәни шигырьләрендә кешене олылау, фикер хөрлеген яклау.

**№ 6**

1. Татар әдәбиятында комедия жанры.
2. “Кайсыгызның кулы җылы...” (Хәсән Туфан лирикасы).
3. Ф.Яруллин иҗаты буенча инша. (Теманы укучы үзе сайлый)
4. Кәрим Тинчуринның “Сүнгән йолдызлар” пьесасында Кайгы һәм Шатлык.
5. Барлык батырлыкның,
   Матурлыкның
   Иҗат итүчесе – халык бит!
   (Һ. Такташ)
6. Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятында яраткан шагыйрем.
7. Хәзерге чор татар прозасы турында минем фикерләрем.

**№ 7**

1. Ф.Әмирханның «Хәят» повестенда хис һәм акыл көрәше.
2. Мәүлә Колый әсәрләрендәге хикмәтләр.
3. “Күпме какканны күтәрде бу милләт...” (Г.Исхакый әсәрләрендә милләт язмышы чагылу).
4. Х.Туфан шигырьләрендәге лирик герой.
5. К. Тинчурин һәм татар театр сәнгате.
6. Аяз Гыйләҗев әсәрләрендә кеше һәм җәмгыять мөнәсәбәтләрен тасвирлау үзенчәлекләре.
7. “Татар бәхте өчен мин җан атармын:
   Татар бит мин, үзем дә чын татармын...” (Г.Тукай)

**№ 8**

1. З.Бигиевнең «Меңнәр яки гүзәл кыз Хәдичә» романында намус һәм акча, җинаять һәм җәза мәсьәләләре.
2. Икмәк кадерен белсәң, җирең таныр;
   Ил кадерен белсәң, илең таныр!
   (Ф.Гыйззәтуллина)
3. Борынгы ядкәрләрдә кеше идеалы.

4. Әмирхан Еники иҗатында Бөек Ватан сугышы темасы.
5. Билгеләми гомер озынлыгын
   Еллар саны, картлык җитүе.
   (М.Җәлил.)
6. С.Хәким иҗаты буенча инша. (Теманы укучы үзе сайлый)

**№ 9**

1. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында Зөләйха образы.
2. Татар әдәбиятында детектив жанр.
3. Т.Миңнуллин – минем яраткан язучым.
4. Гүзәлләрдән гүзәл, изгеләрдән изге,
   Газизләрдән газиз әнкәйләр.
   (Г.Игебаев)
5. М. Маликова иҗаты буенча инша .
6. Утлы еллар поэзиясе.
7. Алтын Урда чоры – татар әдәбиятының яңарыш чоры.

**№ 10**

1. Акмулла- гаделлек һәм мәгърифәт җырчысы.
2. Г.Тукай шигырьләрендә шагыйрь образы.
3. Минем яраткан шагыйрем.
4. Т.Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрендә яшәү һәм үлем фәлсәфәсе.
5. Аксакал һәм егет була белгән
   Чын ир җитми бугай бу илгә.
   (Зөлфәт)
6. Борынгы әдәбиятта әхлак һәм матурлык темасы.

**№ 11**

1. Уеңны уйдырып сал (Дәрдемәнд иҗаты турында инша).
2. Р.Фәйзуллин шигырьләрендә лирик герой.
3. Хакыйкать тудырган фаҗига. (Бөек Ватан сугышыннан соңгы еллардагы татар әдәбиятына күзәтү)

4. Татар әдәбиятында поэма жанры.
5. Ул җырны кайда ишетсәң,
   Туган ил шунда булыр.
   (Рәшит Әхмәтҗанов)
6. Ф.Әмирхан әсәрләрендә тәрбия, әхлак һәм дин мәсьәләләре.
7. Татар әдәбиятында Сөембикә образы.

**№ 12**

1. Татар поэзиясенә Г.Кандалый алып килгән яңалык.
2. М.Фәйзинең «Галиябану» драмасында конфликт бирелеше.
3. Халык авыз иҗаты – мәңгелек хәзинә.
4. Галиәсгар Камал һәм татар театры.
5. Х.Сарьян иҗаты турында инша. (Теманы укытучы үзе тәкъдим итә)
6. Сөембикә турында уйлануларым. (Тарихи әсәрләргә нигезләнеп язарга)
7. «Идегәй» дастанында сурәтләнгән Алтын Урда чоры шәхесләре.

## № 13

1. М.Әгъләмов шигырьләрендә туган ил һәм милләт язмышы.
2. Татар әдәбиятында һәм сәнгатендә Тукай образы.
3. К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» драмасында Мәйсәрә образы.
4. “Дала буйлап кылганнар йөгерә...” (Ә.Еникинең “Әйтелмәгән васыять” әсәре буенча инша. Теманы укучы үзе сайлый).
5. Туган тел,
   Синдә – шатлык җиңеллеге,
   Кайгылар авырлыгы.
   Ата-бабам батырлыгы,
   Аналар сабырлыгы.
   (З.Насыйбуллин)
6. Татар театр сәнгатен үстерүдә Мирхәйдәр Фәйзинең роле.
7. Ф. Әмирхан – психологик анализ остасы.

## № 14

1. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы – әдәбиятыбызның кыйммәтле хәзинәсе.
2. Р.Фәйзуллин иҗатында лирик герой.
3. И.Юзеев иҗатында кеше һәм табигать мөнәсәбәтләренең чагылышы.
4. Т.Миңнуллинның “Әниләр һәм бәбиләр” әсәрендә гомумкешелек кыйммәтләренең чагылышы.
5. Яулар узды.
   Илгә исәннәр дә,
   Үлгәннәр дә җырлап кайттылар.
   (Рәшит Әхмәтҗанов).
6. Алтын Урда чоры татар әдәбиятында мәхәббәт темасы.
7. Р. Миңнуллин – балаларга күңел җылысы өләшүче шагыйрь.

## № 15

1. Борынгы татар әдәбиятында гаделлек темасы.
2. Һ.Такташ иҗатында хатын-кыз матурлыгы.
3. Мәҗит Гафури иҗатында бәхет темасы.
4. М.Хәбибуллин иҗаты буенча инша. (Теманы укытучы тәкъдим итә.)
5. «Идегәй» дастаны – әдәби ядкәребез.
6. К.Насыйри иҗатында халыкчанлык мотивлары.
7. Р.Фәхретдинов иҗатында гомумкешелек кыйммәтләренең чагылышы.

**№ 16**

Акмулла – чичән шагыйрь.

1. Мөхәммәдьяр– хаклык җырчысы.
2. Г.Кутуй иҗаты буенча инша. (Теманы укытучы үзе тәкъдим итә)
3. Иле белән кеше мәртәбәле,
   Иле белән кеше канатлы.
   (М.Әгъләмов)
4. С.Рәмиев иҗаты буенча инша (укучы үзе сайлый).
5. «Идегәй» дастанында көрәшче образы.
6. Татар әдәбиятында көрәш романтикасы.

**№ 17**

1. Татар әдәбиятында мәрхәмәтлелек темасының дини һәм дөньяви яссылыкларда яктыртылуы.
2. “Илең турында уйласаң,
   Гомерең озын була” (Ф.Кәрим).
3. Татар әдәбияты тарихында туган җир темасы.
4. Флүс Латыйфиның “Хыянәт” романында тарихи үткәнебез чагылышы.
5. Габдерәхим Утыз Имәни әсәрләрендә мәгърифәт темасы.
6. М.Мәһдиев – татар авылына дан җырлаучы әдип.
7. Аяз Гыйләҗев әсәрләрендә яшәү фәлсәфәсе.

**№ 18**

1. Гаяз Исхакыйның “Җан Баевич” комедиясендә милли тормыш проблемасының куелышы.
2. Бүгенге поэзиядә заман сулышы.
3. Г.Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» повестенда гореф-гадәтләрнең чагылышы.
4. Кеше үз язмышына үзе хуҗа (Г.Исхакыйның “Көз” повесте буенча).
5. Ф.Кәрим иҗатында яшәү һәм үлем фәлсәфәсе.
6. Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» хикәясендә яктыртылган

милли фаҗига.

7. “Туган җирең чүл булса да
Күңелдә ул гөл генә!
Ватан катлы-катлы булмый,
Ватан була бер генә!” (Р.Фәйзуллин).

**№ 19**

1. Мәхәббәт һәм матурлык хакында сөйләүче әсәрләр. .
2. “Туган-үскән җирем өчен соң тамчы каным фида” (Дәрдемәнд)
3. Үрләр менми, җырлар тумас иде
Җирнең матурлыгы турында.
(С. Сөләйманова)
4. Дәрдемәнд шигырьләрендә фәлсәфи уйланулар.
5. Ф.Яруллин – минем яраткан шагыйрем.
6. “Син – минем тере тарихым
Син – минем киләчәгем”.
(Хәсән Туфан)
Туган тел турында уйлануларым
7. Ш.Хөсәеновның «Әни килде» драмасында күтәрелгән фәлсәфи-әхлакый проблемалар.

**№ 20**

1. И Казаным – алтын бишегем.
2. Г.Исхакыйның мәгърифәтчелек рухы белән сугарылган әсәрләре.
3. “Ни газизрәк – бу ватанмы?
Аһ, туган каумем газиз!” (Дәрдемәнд). Татар әдәбиятында милләт язмышы.
4. Р.Фәхреддин иҗатында тәрбия-әхлак мәсьәләләре.
5. Чакыр, Туфан, безне – яшь буынны-
Җылынырга шигырь янында! (Зөлфәт).
6. “Колыма хикәяләре” – Ибраһим Салаховның җан авазы.
7. Ә.Еникинең «Матурлык» хикәясендә ана һәм бала мәхәббәтенең бөеклеге.